Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Көрнәле Әмзә авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«10» апрель 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 10 апрелендә узган: «2024 елда Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Көрнәле-Әмзә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән парк зонасын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү);

яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (шул исәптән хуҗалык инвентарын саклау өчен йорт сатып алу) мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 30 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 16 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 16 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Көрнәле-Әмзә авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныйрг.

2. 2024 елда Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Көрнәле-Әмзә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле

әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән парк зонасын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү);

яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (шул исәптән хуҗалык инвентарын саклау өчен йорт сатып алу) мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Көрнәле-Әмзә авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Ә. Насыйбуллин

Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Насыйбуллин